# Г.Кариев музее




Татар театрына нигез салучы кеше  Г. Кариевның безнең якташыбыз булуы үзе генә дә нинди горурлык!

Г. Кариев – күренекле татар артисты, педагог, җәмәгать эшлеклесе, драматург . Г.Кариевның исеме мәңгеләштерелде. Казан татар дәүләт яшь тамашачылар театрына ,профессиональ татар театр сәнгатенә нигез салучы, режиссер, артист  Г. Кариев исеме бирелде. Колбай Мораса авылында Г. Кариев музее ачылды. Ул 1986 елда төзелде,  ә 1992 елдан Татарстан Милли музееның филиалы буларак яши башлады.